| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ШУГУРОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ШӨГЕР<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2023 елның 1 марты | №1 |

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 21 октябрендәге 10 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында (15.10.2018 № 28, 29.11.2018 № 35 үзгәрешләр белән)**

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезләмәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Шөгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 21 октябрендәге 10 номерлы карарына ((15.10.2018 № 28, 29.11.2018 № 35 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

күрсәтелгән карарның 2 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) 0,1 процентка карата:

- гараж һәм машина урыннары;

- һәрберсенең мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яки индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир участокларында урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган салым салу объектларында, шул исәптән исемлеккә кертелгән салым салу объектларында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары;».

2.Әлеге карарны Шөгер авылы, Киров ур., 17, балалар бакчасы, Киров ур., 23, «ЛТС» ҖЧҖ - Ленин ур., 32, Шөгер авыл мәдәният йорты, Ленин ур., 35, Шөгер 3 участок хастаханәсе, Горький ур., 4 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар, рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.Н. Гафиятуллин